# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об обращениях граждан в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
28 марта 2025 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 12 мая 2003 года № 16-ЗРТ «Об обращениях граждан в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 24 июля 2014 года № 75-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 5; 2014, № 7; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 38 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2023, № 27 (часть I), № 92 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 4:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Обращение гражданина, изложенное в письменной форме, должно содержать либо наименование органа, в который направляется обращение, либо фамилию, имя, отчество соответствующего должностного лица, либо должность соответствующего лица, а также изложение сути предложения, заявления или жалобы, фамилию, имя, отчество (последнее – при наличии) гражданина, почтовый адрес, по которому должны быть направлены ответ, уведомление о переадресации обращения, личную подпись и дату.»;

б) в части 3 первое предложение изложить в следующей редакции: «В случае, если в письменном обращении не указаны фамилия гражданина, направившего обращение, или почтовый адрес, по которому должен быть направлен ответ, ответ на обращение не дается.»;

в) в части 5 второе предложение изложить в следующей редакции: «В обращении гражданин в обязательном порядке указывает свои фамилию, имя, отчество (последнее – при наличии), а также указывает адрес электронной почты либо использует адрес (уникальный идентификатор) личного кабинета в федеральной государственной информационной системе «Единый портал государственных и муниципальных услуг (функций)» (далее – Единый портал) или в

иной информационной системе государственного органа или органа местного самоуправления, обеспечивающей идентификацию и (или) аутентификацию гражданина (далее – иная информационная система), по которым должны быть направлены ответ, уведомление о переадресации обращения.»;

г) часть 6 признать утратившей силу;

2) пункт 1 части 5 статьи 11 после слова «отчество» дополнить словами «(последнее – при наличии)»;

3) пункт 5 статьи 16 изложить в следующей редакции:

«5) сообщить гражданину о результатах рассмотрения жалобы и принятом по ней решении в срок, установленный законодательством, в письменной форме по почтовому адресу, указанному в жалобе, в форме электронного документа по адресу электронной почты либо при использовании гражданином личного кабинета на Едином портале или в иной информационной системе по адресу (уникальному идентификатору) личного кабинета гражданина на Едином портале или в иной информационной системе или в устной форме по согласованию с ним.»;

4) в статье 20:

а) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Если получатель ответа в коллективном обращении не определен, ответ направляется первому гражданину в списке обратившихся (подписавшихся) граждан в письменной форме по указанному им почтовому адресу, в форме электронного документа по указанному им адресу электронной почты либо при использовании гражданином личного кабинета на Едином портале или в иной информационной системе по адресу (уникальному идентификатору) личного кабинета гражданина на Едином портале или в иной информационной системе.»;

б) в части 3 слова «адресам личных кабинетов на Едином портале» заменить словами «адресам (уникальным идентификаторам) личных кабинетов на Едином портале или в иной информационной системе».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
10 апреля 2025 года
№ 18-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелә торган органның исеме, йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, йә тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле почта адресы, аның шәхси имзасы һәм дата булырга тиеш.»;

б) 3 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Язма мөрәҗәгатьтә аны җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми.»;

в) 5 өлештә икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мөрәҗәгатьтә граждан мәҗбүри рәвештә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), шулай ук җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтергә йә «Дәүләт хезмәт күрсәтүләренең (функцияләренең) һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат

системасындагы (алга таба – Бердәм портал) яисә гражданны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итүче дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасындагы (алга таба – башка мәгълүмат системасы) шәхси кабинетының адресын (уникаль идентификаторын) кулланырга тиеш.»;

г) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 11 статьяның 5 өлешендәге 1 пунктына «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) законнарда билгеләнгән срокта гражданга шикаятьне карау нәтиҗәләре һәм аның буенча кабул ителгән карар турында шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы йә, граждан Бердәм порталдагы яисә башка мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетын кулланганда, гражданның Бердәм порталдагы яисә башка мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча электрон документ рәвешендә яисә, аның белән килештереп, телдән хәбәр итәргә.»;

4) 20 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Күмәк мөрәҗәгатьтә җавап җибәрелергә тиешле зат билгеләнмәгән булса, җавап мөрәҗәгать иткән (имза салган) гражданнар исемлегендәге беренче гражданга ул күрсәткән почта адресы буенча язма рәвештә, ул күрсәткән электрон почта адресы йә, граждан Бердәм порталдагы яисә башка мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетын кулланганда, гражданның Бердәм порталдагы яисә башка мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча электрон документ рәвешендә җибәрелә.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Күмәк мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турында үтенеч берничә мөрәҗәгать иткән (имза салган) зат тарафыннан белдерелгән очракта, җавапның күчермәсе алар күрсәткән почта адреслары, электрон почта адреслары йә Бердәм порталдагы яисә башка мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетларының адреслары (уникаль идентификаторлары) буенча аларның һәрберсенә җибәрелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 10 апрель
№ 18-ТРЗ